**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 13 апрель № 218

г. Казань

Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве зурлыгын билгеләү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве буенча ташламалар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында» 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве зурлыгын билгеләү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәтне дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләргә, иҗтимагый оешмаларга арендага биргәндә аренда түләвенең базар бәясенең 50 проценты зурлыгында ташлама бирелә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарларын үз көчен югалаткан дип танырга:

«Дәүләт мөлкәтен арендага бирүдән керемнәрне тәэмин итү чаралары турында» 2003 ел, 20 март, 159 нчы;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мөлкәтен арендага бирүдән керемнәрне тәэмин итү чаралары турында» 2003 ел, 20 март, 159 нчы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2005 ел, 09 сентябрь, 444 нче;

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте өчен аренда түләве зурлыгын билгеләү турында» 2012 ел, 11 февраль, 99 нчы.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 13 апрель, 218 нче карары белән расланды

Теркәлгән Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен аренда түләве зурлыгын билгеләү тәртибе

1. Бу Тәртип Татарстан Республикасы милкендә булган мөлкәт өчен (алга таба – мөлкәт) аренда түләве зурлыгын билгеләү буенча мөнәсәбәтләрне җайга сала

Әлеге Тәртипнең гамәле Татарстан Республикасы җир кишәрлекләрен, су объектларын һәм бүтән табигый ресурсларын арендага бирү белән бәйле мөнәсәбәтләргә таралмый.

2. Сатулар (конкурслар, аукционнар) нәтиҗәләре буенча арендага бирелгән мөлкәт өчен аренда түләве Федераль антимонополия хезмәтенең «Аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләре, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә карата хокуклар күчүне күздә тоткан бүтән шартнамәләр төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе һәм әлеге шартнамәләрне төзү конкурс рәвешендә сатулар үткәрү юлы белән гамәлгә ашырылырга мөмкин булган мөлкәтләр төре исемлеге турында» 2010 ел, 10 февраль, 67 нче боерыгы белән расланган Аренда шартнамәләре, түләүсез файдалану шартнамәләре, мөлкәт белән ышанычлы идарә итү шартнамәләре, дәүләт һәм муниципаль мөлкәткә карата хокуклар күчүне күздә тоткан бүтән шартнамәләр төзү хокукына конкурслар яки аукционнар үткәрү тәртибе белән билгеләнгән сатулар үткәрү процессында билгеләнә.

3. Сатулар (конкурслар, аукционнар) үткәрмичә генә арендага бирелгән мөлкәт өчен аренда түләве зурлыгы, шулай ук сатулар (конкурслар, аукционнар) үткәрү өчен кирәкле аренда түләвенең беренче зурлыгы бәяләү эшчәнлеге турында законнар нигезендә үткәрелә торган аренда түләвенең базар бәясен бәяләү нигезендә билгеләнә.

4. Аренда түләве зурлыгы коммуналь хезмәтләргә түләү өчен, техник хезмәт күрсәтүгә, арендага бирелгән мөлкәтне саклауга һәм бирелә торган мөлкәтне тоту һәм эксплуатацияләү белән бәйле килеп чыга торган чыгымнарны, шулай ук мөлкәтне мәҗбүри иминиятләү, җир кишәрлегеннән файдаланган өчен түләү өчен чыгымнарны үз эченә ала.